ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2021 елның «31» мартыннан № 159

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 ел, 25 сентябрь, 406 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 ел, 5 ноябрь, 999 нчы карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Яңа Чишмә муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 ел, 25 сентябрь, 406 нчы карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү Тәртибенең 2 нче бүлегенең 2.1 пунктына (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 17.01.2014 № 15, 14.02.2017 № 84, 19.01.2018 № 25, 16.09.2019 № 230, 21.04.2020 № 94, 03.02.2021 № 46 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2.1 пунктның «б)» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) с 1 апреля 2021 года расчет среднедушевого дохода семьи при назначении дополнительной компенсации части платы, взимаемой с родителей

(законных представителей) за присмотр и уход за детьми в образовательных организациях, реализующих образовательную программу дошкольного образования, семьям со среднедушевым доходом до 20,0 тыс.рублей исходя из суммы доходов членов семьи за последние 12 календарных месяцев, предшествующих шести календарным месяцам перед месяцем подачи заявления о ее назначении;

2021 елның 1 апреленнән җан башына уртача кереме 20,0 мең сумга кадәр булган гаиләләргә мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны караган өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган өстәмә компенсацион түләүнең бер өлешен билгеләү өчен хисап гариза бирү ае алдыннан алдагы алты календарь аена кадәр килъче соңгы 12 календарь ай өчен гаилә әгъзаларының керемнәре суммасыннан чыгып санала;».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http//pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фәсахов